**Тема :** “Ата-анага, өлкәннәргә хөрмәт”

**Максат:**
1.Укучыларны “Ата-анага, өлкәннәргә хөрмәт” дигән темага уйланырга мәҗбүр итеп тормышта эти- әниләрен, өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәтү.
2. Укучыларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү.

**Эпиграф*:*** ***”...Дөньяда иң бәхетле һәм рәхәт яшәүче кеше – ул әти- әнисенә, олыларга изгелек эшләүче зат”.***

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәсе:**
- Ата- ана каршында булган бурычларыбызны ачыклау.
- Аларга карата ярату, җаваплылык хисләрен тәрбияләү.
- Ата- аналар белән аралашу тәләпләрне белү.

**Дәрес барышы**

**I. Уку мәсьәләсен кую.**
- Кечкенә генә хикәяне тыңлагыз, шуннан чыгып, бүгенге дәреснең темасын үзегез әйтеп бирегез:

*Ананың бердән- бер улы искиткеч чибәр кызга өйләнгән, туган йортына алып кайткан, ләкин хатынның йөрәге урынында күкрәгендә кара таш булган. Әнкәсен сөймәгән килен иренә: “Анаң өйгә кермәсен, өй алдында яшәсен”,- дигән. Улы әнисен өй алдына күчергән, өйгә кермәскә кушкан. Ана кеше каты бәгерле киленнең күзенә дә күренергә курыккан.*

*Аңа да риза булмаган яшь хатын, иренә анасын сарайга урнаштырыга кушкан. Улы әнисен сарайга күчергән. Бервакыт чәчәк атып торган алмагач төбендә утырган килен ананың сарайдан чыгып баруын күреп, ачуыннан ярсып ире янына йөгереп килгән дә: “Минем белән яшисең килә икән, анаңны үтер, йөрәген күкрәгеннән алып, миңа китер!”, - дигән.*

*Улының йөрәге икеләнмәгән- хатынның матурлыгы аны сихерләгәндәй булды. Күкрәгеннән алып, әнисенең йөрәген өрәңге яфрагына куеп, хатыны янына атлап барганда, зур ташка абалана. Канга баткан ана йөрәге:”Улым, бәгърем, бик каты бәрелгәнсең- утыр, ял итеп ал, авырткан җиреңне угала...”,- диеп пышылдый.*

*Улы үксеп- үксеп елап җибәрде, әле кайнар йөрәкне учына алып, әнисенең күкрәгенә салды. Бик үкенде- беркайчан да, беркем дә аны әнисе шикелле яратмаган һәм яратмыячак икәнен аңлады! Ана йөрәге улын кызыганып, аны бәхетле итәсе килеп, яңадан терелә. Әнисе торып, улының башын күкрәгенә сала.*

*Мәхәббәт исерелегеннән котылып, чибәр хатыны янына кайтмады ир.*
*Бәгер катты. Анасы белән бергә киттеләр алар дала буйлап һәм ике көчкенә тауга аверелделәр. Иң беренче кояш нурлары аларга көндә сәлам бирәләр.*

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**
- Димәк, бүгенге дәреснең темасы... (Әни турында- ата-анага, өлкәннәргә хөрмәт).

**III. Уку мәсьәләсен чишү.**

**1. “Ни өчен без өлкәннәрне, карт кешеләрне хөрмәт итәргә тиешбез?” дигән сорауга җавап табу.**
- Әйе, балалар, җир йөзендә иң әйбәт, иң ягымлы, иң кадерле кешеләребез – ул безнең әниләребез, әтиләребез, әби- бабайларыбыз. Дөньяда иң ышанычлы, иң кечле- безнең әтиләребез. Хөрмәткә иң лаеклы кешеләр- әби- бабайлар, өлкәннәр. Без аларны яратырга, аларга һәрвакыт булышырга тиешбез.
- Ни өчен без әти- әниләрне хөрмәт итәргә тиешбез? (Укучылар җавабы):
- Алар безгә яшәүне бүләк иттеләр.

- Әти- әниләр безне бик яраталар.
- Безне авырлыклар белән үстерделәр.
- Алар безне ашаталар, эчертәләр, киендерәләр, укыталар.

Укытучының нәтиҗәсе.

- Өлкән кешеләр бу дөньяда күпне күргәннәр, шуңа күрә аларның тормыш тәҗрибәсе зур. Алар яшьләргә үзләренең акыллы киңәшләрен бирә алалар. Аларда тәҗрибә, акыл һәм хикмәт яшьләргә караганда күбрәк.

- Бүгенге чорда әти-әниләрне, өлкән яшьтәге кешеләрне олылау һәм аларга карата хөрмәт күрсәтү акырын - акырын югалып бара. Без моны өйдә дә, урамда да һәм җәмагәть транспортында да күрәбез. Ни өчен яшьләр хәзерге вакытта олыларны хөрмәт итмиләр? Ни өчен балалар әти – әниләрен саннамыйлар, аларга хәтта кычкыралар.

**2. Төркемнәрдә эшләү.**

**1нче бирем. Уен "Мин башлыйм, син дәвам ит".**

- Шәфкатьлелек сүзләре белән бәйләнешле мәкальләр белән танышу (мәкальләрне тәрбияче башлый, укучылар дәвам итә).

- Олылысаң олыны, ... *олыларлар үзеңне.*
- Әткәй – шикәр, әнкәй – ... *бал.*
- Яктылык – кояш янында, яхшылык ... *ана янында.*
- Ана күңеле балада, бала күңеле ... далада.
- Баланың бармагы авыртыр, ананың ... *йөрәге авыртыр.*
- Ана янында бала ... *ятим булмый.*

  Ата-ана гаебен тикшерү... *бала эше түгел.*
- Атаңны башында тот, *аңаңны ... учыңда тот!*
- Ачтан үлсәң дә, ата-анаңны …*ташлама!*
- Ата-ананы тыңлаган — *адәм булган*, тыңламаган — … *әрәм булган.*
- Атасын алдаган …*илен дә алдар.*

**2нче бирем**

- "Әни" ("әти") дигән сүзләрне ишеткәч, сездә нинди *ассоциацияләр* (уй, хисләр) барлыкка киләләр? Шул хисләрне бер сүз белән генә әйтеп бирегез. (Матурлык, кул җылысы, тынычлык, шәфкатьлелек, ярдәмләшү, кызыгану, ярату...).

- Хәзер сезгә бер әни турында гыйбрәтле өзек тәкъдим итәм. Тыңлагач, аңа исем кушарсыз.

*Минем әнием бер генә күзле иде. Шуңа күрә кешеләр янында мин аннан ояла идем. Гаиләбезне җитеш тормышта яшәтү өчен, әни мәктәп ашханәсендә эшләде.*

*Бервакыт мәктәптә, хәлемне белү өчен, әни минем яныма килде. Ә мин исә оятымнан кызардым. Күңелемә авыр булды. Ничек шулай классташларым алдында мине оятка калдыра алды икән ул?! – дип уйладым эчемнән генә. Һәм ачу катыш нәфрәт белән карап, берни дәшмичә китеп бардым. Икенче көнне классташларымның берсе:*

*- И-и, синең әниеңнең бер күзе юк икән бит, - дип, мине мыскыллады.*

*Миңа шулкадәр авыр булды, хәтта: «Әнием бөтенләйгә юкка чыкса иде», - дип тә теләдем.Соңрак, өйгә кайткач аңа:*

*- Мине болай оятка калдырганчы, үлсәң яхшырак булыр иде, - дидем.*

*Әнием бер сүз дә дәшмәде. Ачудан ярсу сәбәпле, әнигә нәрсәләр әйтүем турында уйламадым да. Миңа барыбер иде. Аның хисләре, нәрсә кичерүе мине кызыксындырмады да. Хәтта аны өйдән куып чыгарасым да килде.*

*Мәктәпне тәмамлагач, Бишкек шәһәрендәге югары уку йортларының берсенә укырга кердем. Университетны тәмамлап, диплом алгач өйләндем. Балаларыбыз туды. Тормышның тәмен, ямен тоеп яши бирдем…*

*Бервакыт Бишкекка әнием килде. Аның әле оныкларын күргәне юк иде. Ишегалдына килеп кергәч, аңа бөтен кеше игътибар итте.*

*- Балаларымны куркытырга ничек җөрьәт итәсең? Ычкын моннан!!! – дип акырдым мин аңа.*

*Әни, пышылдап кына гафу үтенде дә, башын аска иеп, тиз генә чыгып китте. Бер көнне классташлар белән очрашу кичәсенә чакыру кәгазе алдым. Хатыныма: «Командировкага китәм, тиздән кайтырмын,» - дидем.*

*Дусларым белән очрашудан соң, кайчандыр үзем яшәгән, балачагым үткән йортка киттем. Күршеләребез әниемнең үлгәнлеген хәбәр иттеләр... Әмма күңелемдә бу хәбәргә карата бернинди дә үзгәреш булмады. Җаным битараф иде. Күршеләребез әниемнең миңа дип язган хатын тапшырдылар. Әниемнең соңгы сүзләре болай иде:*

*«Улыкаем, мин һәрвакыт сине уйлыйм...*

*Теге вакытта кисәтмичә килеп, балаларыңны куркытып, үзеңне кыен хәлгә калдыруым өчен гафу үтенәм. Классташлар белән очрашуга чакыру кәгазе җибәргәннәрен белгәч, мин бик сөендем. Ләкин, авыруым сәбәпле, бу очрашуга мин бара алмамдыр инде. Балачагыңда классташларың янында кыен хәлгә калдыруым өчен, мине гафу ит инде, улым...*

*Күптәннән сиңа бер вакыйганы сөйлисем килә иде, менә тыңла әле. Кечкенә вакытыңда, әле йөрергә генә өйрәнгәндә, син егылып, бер күзеңне чыгарган идең. Синең авыртынуыңны, газаплануыңны күрү шулкадәр авыр иде. Бер генә күз белән калсаң, бу газапны мин кичерә алмас идем. Шуңа күрә күзләремнең берсен мин сиңа бирдем. Синең зур итеп ачылган күзләреңне, бәхетле йөзеңне, елмаюыңны күрү бәхет иде.*

*Улым, шуны бел: ни генә булса да мин сине яратам.*

*Сине яратучы әниең».*

*... Мин тораташтай булып катып калдым, җанны укенү телде, ләкин соң иде инде, бик соң ...*

- Бу хикәягә нинди исем кушар идегез? (Ана күзе. Ана күнеле. Рахимсез бала...)
- Кайсы мәкаль риваятнең төп фикерен ачыклый? (Баланың бармагы авыртыр, ананың йөрәге авыртыр. Ачтан үлсәң дә, ата-анаңны ташлама!)
- Сукыр ананың тышкы кыяфәтең сүрәтләп бирегез.
- Ананың эчке дөньясы турында нәрсә әйтә аласыз?
- Сукыр ананың улына нинди үгет- нәсыйхәт бирер идегез?
  - Ана баласы эчен күзен дә, кирәк икән, гомерен дә бирергә әзер.
  - Әнигә авыр сүз беркайчанда әйтмә.
  - Ананы рәнҗеткән бала бәхетле булмас.

- Бүгенге көндә күпме ата-ананың балалары тарафыннан кимсетелеп, йортларыннан куып чыгарылуы, картлар йортына илтеп ташлаулары турында, ул гына да түгел, хәтта үтерүгә барып җиткән очракларны да көндәлек матбугат битләренннән дә, зәңгәр экраннар аша да күрепишетеп торабыз. Хәзер шул темага караган кайбер мәгълүматларны карап китик әле.

Әйе, ата–ананың хаклары бик зур. Газизләрең нинди генә хәлдә булсалар да, “Уф” та дип әйтмә, чөнки әниең сине авырлык өстенә авырлык белән 9 ай күтәргән, этиең шул вакытта сезне ризыкландырган, инде син дөньяга килгәч, шатланган. Ризыгың — әниеңнең күкрәк сөте, этиеңнең нык кулы — бишегең булган. Тәрбия биргәннәр, гыйлем биргәннәр, өс–башыңны караганнар, хәвеф–хәтәрдән саклаганнар. Бала чагында сине чиста итеп тотканнар, астыңны җыйганнар, төн йокыларын калдырып, сине караганнар. Авырсаң, шифасын тапканнар. Ялгышсаң, үгет-нәсыйхәт биргәннәр, догада булганнар.

- Тагын бер хикәя искә төште: *Әтисен бик хөрмәтләгән икән, картайгач, күтәреп йөргән, чиста–пакь тоткан, йомышын үтәгәндә дә җирәнмәгән бер егет. Шулай итеп гомер кичергәннәр. Бервакыт йокларга ятканда бу егет: “Мин әниемне дә карадым, әтиемне дә тәрбиялим, инде бурычымны үтәгәнмендер”, — дип уйланып, йокыга киткән.*

*Төшендә моңа: “Әлбәттә, син бурычыңны үтисең. Әти–әниең сине карагандай карыйсың. Вә ләкин аерма шунда: әти–әниең сине бакканда, сине пакь тотканда, асларыңны җыйганда, тәрбияләгәндә, бу эшкә бурыч, дип карамадылар, шатлана–шатлана дәвамлы, тәүфыйклы булсын, миһербанлы–шәфкатьле булсын, дип, догада булдылар. Әмма монда бер аерма бар.*

*Алар караганда дәвамлы булсын дип, ә син тизрәк бетсен иде, дигән уйдан арына алмыйсың”, — дигән аваз килә.*

- Әйе, безнең бу якты дөньяга килүебезгә ата-аналар сәбәпче булган. Җил-давылларга тидермичә, ышыклап, авырган вакытларыбыз да төннәрен йокламыйча безне үстергәннәр, кеше итәргә тырышканнар, безнең ата-аналарыбызга карата булган хакларыбыз бик зур, ата-ана хакын түләп бетерергә мөмкин түгел. Без бу якты дөньяда яшәгән вакытта аларның ризалыгын алырга тиешбез. Әмма ни үкенеч, күпчелек адәм балалары үзләрен тудырып үстереп кеше иткән ата-аналарын рәнҗетәләр, исерек хәлләрендә кайтып ата-анасына кул күтәрәләр, соңгы акчаларын тартып алып тагы шул шәйтан суын эчәләр, баткаклыкка кереп чумганнан чумалар, ә эти кеше белән әни кешенең йөрәге өзгәләнә, ул баласын менә менә шуның өчен үстердеме?

Кайбер балалар ата-аналарына өйләрендә урын калмагач аларны җиһаз шикелле картлар йортына илтеп тапшыра, мөгаен мондый бәндәләрнең йөрәкләре юктыр, аның урынына анда таштыр.

Без гомеребез буе ата-аналарыбызга игелек кылсакта, аларның хакларын түләп бетерә алмыйбыз. Без сабый вакытта алар безне тәрбиялиләр, төннәрен йокысыз үткәрәләр, бердә авырсынмыйлар, без үсеп ныгыгач көннәрдән бер көнне аларның егәре бетә, инде хәзер ата-аналарыбызны без тәрбияләргә тиеш булабыз, ничек алар безне тәрбияләгән булса бездә шулай ук җавап кайтарырга тиеш булабыз.

- Хәзер сезгә ата-ананы хөрмәтләү турында бер хикмәтле этинең улына биргән нәсыйхәтен тәкъдим итәм (“Кабуснамә”. Габделкаюм Насыйри тәрҗемәсе). Иһтибар белән тыңлагыз.

- Әй улым! Ата-ана хакларын хакла, аларны олыла, хөрмәтлә. Шул чагында син үзеңне дә кадерле иткән булырсың, зур дәрәҗәләргә ирешерсең. Алар үз теләкләренә ирешү өчен генә түгел, бәлки сине дөньяга китерү өчен дә кавыштылар. Ата-анаң булмаса, син дөньяга килмәс идең.
- Аллаһ Тәгалә шулай итеп яраткан инде, ата-анаң, сиңа бирәр авырлык, зыян килмәсен дип, синең өчен үләргә дә әзер торалар. Әгәр син ата-анаңа тупас, дорфа булсаң, аларга начарлык эшләсәң, ул чагында син беркайчан да яхшылыкка лаек булмассың.
- Газиз ата-анасыннан изгелек күреп тә, аны аңлый, бәяли белмәгән кеше башкаларның да яхшылыгын күрә белмәс. Әгәр балаңның үзеңә хөрмәт күрсәтүен теләсәң, иң элек ата-анаңны хөрмәтлә.

- Димәк, ата-анага кадер, хөрмәтне күбрәк күрсәтсәң, аларның теләкләре тизрәк кабул булыр, бәрәкәте сиңа ирешер, син бәхетле булырсың.

**Зче бирем “Алдагы риваяттән нинди гыйбрәт алып була?” дигән сорауга җавап бирү.**

*Бер бәдәви гарәпләр гаиләсендә бабай картаеп бетә дә гаиләсенә кирәкми башлый. Шул вакытта бабайның малае әтисен аркасына менгереп утырта да чүлгә таба илтә башлый. Чүлгә таба барганда бабай көлә- елый шундый сүзләр әйтә: "Җитте, җитте, үземә дә килеп җитте”. Бу хәлне ишеткән- күргән кешеләр сорыйлар: "Әй бабай нәрсә килеп җитте соң?” Улының аркасында утырган бабай җавап бирә: "Беләсезме, мин дә яшь чагымда бу улымның күз алдында үземнем картаеп беткән әтиемне нәкъ шулай ук чүлгә үлергә илтеп ташлаган идем. Күрәсезме, хөрмәтле кардәшләрем, ничек син эти-әниеңә мөгамәлә кыласың, нәкъ шундый ук мөнәсәбәтне үз балаларыңнан күрәсең. Алланың рәхмәтенә ирешәсең килсә, балаларыңа дөрес тәрбия бирәсең килсә, нәтиҗәдә бәхетле булам дисәң, эти-әниләреңә матур мөнәсәбәт күрсәт, игелелекле бул.*

- Бу риваяттән нинди гыйбрәтләр алып була? (Укучылар җавабы):
- Ата-ананың кадерен белмәсәң, киләчәктә үз балаларың да синең кадереңне белмәсләр.
- Җәмгыятебез сәламәт булсын өчен гаиләләре дә ныклы булырга тиеш. Ата-анага хөрмәт булганда гаиләләр дә ныклы булалар. Аларны хөрмәт итү гаиләдә өлкәннәрнең ролен үстерү дигән сүз, чөнки алар үсеп килүче буынга акыллы киңәшләрен бирәләр. Кайбер кешеләр ати-әниләр исән-сау булуының кадерен белеп бетерми. Ә бит бу – Аллаһның зур рәхмәте һәм олы нигъмәте. Үги әниләрен дә бик хөрмәт итеп яшәүчеләр дә байтак! Мондый мөнәсәбәт кешенең

табигатенә үк салынган. Ана кешегә аеруча игътибар кирәк, чөнки төп авырлык аның җилкәсенә төшә: йөкле булуның һәм бала табуның авырлыгы, баланы ашату-эчертү, тәрбияләүне ул гел үз өстенә ала.

**4нче бирем. Ата-аналарыбыз каршында булган бурычларыбызны ачыклау.**
- Хәзер ата-аналарыбыз каршында булган бурычларыбызны карап үтик. Укучылар җавабы:
Әти- әниләрне чын күнелдән яратырга, яратканны сиздерегә.
Әти- әниләрне тыңларга, алар кушканны эшләргә.
Әти- әниләргә ягымлы, "тәмле телле" булырга.
Әти- әниләр белән тупас булмаска.
Әти- әниләргә кирәк вакытта ярдәм итәргә.
Әти- әниләрне, картлыклары җиткәч, ташламаска, ялгыз калдырмаска.

**3. Ата-аналарыбыз каршында булган бурычларыбызны тирәнрәк өйрәнү.**
1. *Ата-анага карата салкынлык күрсәтмәү.*
" Бөтен йөрәгең белән үз әтиеңне хөрмәтлә һәм үз әниеңнең бала тудыргандагы газапларын онытма. Син алардан туганыңны онытма: һәм син аларга бурычыңны кайтара аласың. Хайваннар гына вакыт үтү белән ата-аналарын онытлар. Ата-анага якынлыкны сизмәү һәм аны күрсәтмәү- начарлыктыр. Ата-анага мәхәббәтне бүтән бернинди дә мәхәббәт алыштыра алмый. Ата-ана йортына сирәк бару салкынлыкның ачык мисалы. Аларны кыерсытканда башкалар каршында аларны якламау улларча кайгырту булмауны күрсәтә.

2. *Ата-ананы тыңлау,аларга буйсыну.*Ата-аналар балалар өчен изге затлар. Әгәр бала ата-ана йортында тыңлаусыз, сансыз икән, ул бер җирдә дә: хезмәттә дә, шәхси тормышта да шундый була. Ата-ана йортында, әле ул җәмәгать тормышына чыкканчы, ата-ана бала өчен җитәкче урынында. Әгәр бала берсүзсез ата-ана теләген үтәргә гадәтләнмәгән икән, аның язмышына мөнәсәбәтле чит кешеләрнең теләгенә буйсыну авыр булачак. Акыллы ата-аналар балалары өчен күп нәрсәләр эшлиләр, шуңа күрә балаларның аларның теләген үтәүләрен таләп итәргә хаклары бар. Балалар мөстәкыйль тормыш белән яши башласалар да,ата-ана өчен һаман бала булып калалар һәм ата-ана алдындагы бурычлардан азат ителмиләр.

*3.Ата-аналар белән тупас мөнәсәбәттә, алар белән ачуланышуда булмау.* Ата-анага хөрмәт күрсәтмәү бик зур кимчелектер. Аларга төртмәле, тавыш күтәреп, мыскыллы елмаеп җавап бирү, бер сәбәпсез аларга каршы килү, ата-ана кимчелекләрен күрсәтеп,аларны гаепләү,туганнар арасында алар турында начар фикерләр әйтү, аларны дин мәсьәләләрендә ачулану зур хатадыр.

4. *Ата-ананың изгелеген, теләк итүләрен санга сугу.*
Ата-ана теләк итүләренең көчен санга сукмаган балалар начарлардыр. Ата-ананың хәер-фатихасына йола итеп кенә караган балалар да аларны аеруча рәнҗетә.

*5. Ата-ананы үпкәләтмәү, ачуланмау, каргамау.*
Ата-анасының исәнлеге өчен теләк итмәгән бала үзенең яхшы яшәвен теләмәгән була, чөнки ата-ананың исәнлеге баланың яхшы тормышының нигезе булып тора. Баланың ата-ананы каргавы иң усал кешегә генә хас һәм ул көчсез. Ул гадәттә, әйткән кешенең үз башына төшә.

6. *Ата-ана киңәшен тоту.*
Ата-аналар яши-яши тормыш тәҗрибәсе һәм акыл туплаганнар. Шуңа күрә алар биргән киңәш һәм үгетләр начар була алмый. Һәр яңа эш башлаганда ата-ана киңәшен сорау балаларның бурычы. Ата-ана үгетләренә дәшмичә калу тиеш эш түгел. Чит кеше сүзләрен онытырга мөмкин, әмма ата-ананыкын беркайчан да онытмаска кирәк. Ата-ананың яхшы киңәшләрен ул үлгәч тә онытмаска кирәк.

7. *Ата-ана рөхсәтеннән башка өйдән китмәү.*
Ата-ана йортында яшәүче балигъ булган балалар кайда һәм күпме вакытка китүләре турында кисәтергә тиешләр. Ата-ана йортыннан үз белдеге белән усалланып чыгып киткән бала зур шелтәле була. Моның белән ул ата-ананы тирән кайгыга сала.

8. *Ата-ана йортыннан аерылмау.*
Ата-ана ризалыгыннан башка туган нигездән аерылу төрле уңайсызлыклар китереп чыгарырга мөмкин, ялгыз калган ата-аналар да баладан аерылу кайгысы белән яши.

9.*Ярдәмгә мохтаҗ ата-аналарны картлыкларында ялгыз калдырмау.*
Бәхетсезлектә ата-ананы ялгыз калдыру - зур кимчелектер. Үз ата-анаңнан оялып, аларның сиңа күрсәткән яхшылыкларын оныту түбәнлек санала.

10. *Ата-анага кычкырмау, кул күтәрмәү.*
Ата-анага кул күтәрү - иң зур җинаятнең берсе. Ата-ана балаларыннан кыерсыту күрсә, ул җәзасыз үтмәсен белеп, алар өчен борчылалар. Әмма тупас балалар аңга килмиләр.
- Олыларга хөрмәт күрсәтүне без ничек аңларга тиеш һәм ул нәрсәдә чагыла?
- Иң беренче чиратта олыларга хөрмәт күрсәтү очрашкан вакытта аларга беренче булып сәлам бирүдә күренә.
- Әти- әни чакырса- бала яннарына йөгереп килергә тиеш.
- "Кечкенә олыга, узып баручы, утырып торучыга, әз төркем күп төкемгә (беренче булып) сәлам бирә”- диелгән бер ышанычлы чыганакта.
- Ашаган вакытта ризык кабул итүне иң беренче өлкән кеше яки хөрмәтле кеше башларга тиеш.
- Әгәр дә кешеләргә берәр нәрсә бирергә туры килсә, мәсәлән, сулы савытны, ризыкны, башта өлкән кешедән башларга кирәк.
- Сүз башлаган вакытта да әдәп буенча беренче сүзне олыларга бирәләр.
- Олылар сөйләшкәндә, аларның сүзен бүлү бик зур тәртипсезлек.

**4. Изге Коръән китабыннан.**
- Аллаһ Тәгалә изге Коръән китабында әйтә:

- ***“ Раббың Үзенә генә гыйбадәт кылырга һәм ата- анага игелек эшләргә боерды. Әгәрдә аларның берсе яки икеседә синең яныңда картлыкка ирешсәләр, син аларга “уф” дип тә әйтә күрмә, аларга кычкырма, ә яхшы мөләем сүзләр генә сөйлә. Аларга үзеңнең рәхим- шәфкать канатларыңны җәй һәм дога кыл: “Ий, Раббым, алар мине бала чагымда ничек рәхим- шәфкатьлелек белән тәрбияләп үстергән кебек, Син дә аларга рәхмәт кыл!”***

/Исра- 23, 34/

- Әйе, ата–ананың хаклары бик зур. Газизләрең нинди генә хәлдә булсалар да, “уф” та дип әйтмә, чөнки әниең сине авырлык өстенә авырлык белән 9 ай күтәргән, әтиең шул вакытта сезне ризыкландырган, инде син дөньяга килгәч, шатланган.

Ризыгың — әниеңнең күкрәк сөте, әтиеңнең нык кулы — бишегең булган. Тәрбия, гыйлем биргәннәр, өс–башыңны караганнар, хәвеф–хәтәрдән саклаганнар. Бала чагында сине чиста итеп тотканнар, астыңны җыйганнар, төн йокыларын калдырып, сине караганнар. Авырсаң, шифасын тапканнар. Ялгышсаң, үгет-нәсыйхәт биргәннәр, догада булганнар.

Элеккеге кешеләрнең берсе ата- анасы аның тәрбиясендә калгач, болай дип Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать иткән: “Ий, Раббым, минем нинди изгелекләрем аркасында әти- әнине карау- тәрбияләү бәхетенә ирештем?!”

**5. Хәдисләр.**
- Мөхәммәд Пәйгамбәрнең (гәләйһи әссәләм) хәдисләрен укып, алар турында үз фикерләрегезне әйтегез. Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.с) әйтә:

- ***“Оҗмах әниләрнең аяк асларында”.***

- Әнисен хөрмәт иткән, тыңлаган, аның ризалыгын аласы килгән баланың киләчәктәге урыны-өҗмах.

- ***«Әти-әниләрегезгә изгелек кылыгыз, балаларыгыз да сезгә игелек кылучы булырлар».***

- Балалар әти – әниләренә яхшы мөнәсәбәттә яки начар мөнәсәбәттә булсалар, аларның балаларыда үзләренә шундый ук мөнәсәбәттә булачак.
Әгәр дә кеше яшь вакытта үзенең әти – әнисен саннамаса, рәнҗетсә, килер бер көн ул үзенең балаларыннан да үзенә карата шундый ук мөгамәләне күрәчәк.

- ***“Ата- аналарын риза кылучы балалардан Аллаы Тәгалә дә риза булачак”.***

- Бу хәдисләр олыларга хөрмәт күрсәтү Ислам динендә зур урын алып торганлыгын аңлата. Картлар йортында түгел, уллары, кызлары, оныклары белән кадер–хөрмәттә гомер кичерсеннәр. Ата-ананы тәрбияләү бөек эш. Әгәр берәү шул мактаулы эшкә лаек булып та, шуны ихлас белән башкарып чыга алмаса, аңа хурлыктан башка нәрсә калмый. Ата-анасы исән вакытта аларның ризалыгын алган кеше зур дәрәҗәсенә ирешәчәк, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алачак.

**IV. Рефлексия. (Йомгаклау).**
**-** Дәреснең темасын искә тешерегез.
- Әти- әниләргә, өлкәннәргә карата нинди гыбрәтләр алдыгыз?
("Әти – әниләрегезгә игелекле булыгыз, балаларыгыз да сезгә игелек кылучы булырлар”).
- Димәк, без һәрвакыт әти-әниләребезгә, өлкәннәргә мәрһәмәтле һәм шәфкатьле булырбыз. Йомгаклап шуны әйтергә кирәк*: ”...дөньяда иң бәхетле һәм рәхәт яшәүче кеше – ул әти-әнисенә, олыларга изгелек эшләүче зат”.* /Эпиграф белән танышу/
- Ата-ананың хакын үтәү бурычлы гамәлләрнең берсен кылу була. Аларның сиңа кушкан һәрбер эшләрен эшлә. Ата-анаңны чын күңелеңнән сөй, аларга һичбер вакытта каршы сүз әйтмә. Орышсалар, аларның хәтерләре калырлык сүз белән җавап бирмә.
Алар сөйми торган кешеләр белән катышма. Аларның якын күргән дусларын яратмасаң да, дошман күрмә. Аларның күзләреннән югалып, озак, билгесез җирләрдә йөрмә. Алар яратмаса да, бер эшне кылырга кирәк булса, бик түбәнчелек белән генә ризалыкларын сора. Аларны ничек булса да һәрвакыт үзеңнән риза кылырга тырыш.
Алардан аерым бер урында торсаң, һәркөнне барып аларның хәлләрен сораш. Йомышлары юкмы, кирәк нәрсәләре булып аптырап тормыйлармы? Һәркайсын сорашып кулыңнан килгән кадәр аларга ярдәмче бул. Еш-еш йортыңа китереп аларны кунак ит. Хәсрәтләре булса, юат, чирләсәләр, яннарыннан китмә, һәрвакыт хезмәтләрендә бул.
Алар картаеп эш эшли алмас булсалар, аларны тәрбия кылудан тартынма. Аларны кеше ишегенә чыгарма, үзең мохтаҗ булсаң да, бу эштән бик саклан. Өс-башларын керле, пычрак йөртмә. Йортыңда булган ризыгың белән аларны ашат. Тышка да чыгып йөри алмаслык дәрәҗәгә килсәләр дә, һичбер авырсынма. Аларга балаларыңнан каты сүз әйттермә, алар янында һичбер әдәпсезлек кылма, тәкәбберләнеп (горурланып) йөрмә.
Үзләренә һич караңгы чырай күрсәтмә. Менә шулай итеп аларны тәрбия итсәң генә аларның хакларын җиренә җиткереп үтәгән булырсың. Әгәр шундый эшләрнең берәрсендә кимчелек кылсаң, яисә, аларны шулай тәрбияләп тә, авырсынып башкаларга зарлансаң, син аларны Аллаһы Тәгалә кушканча тәрбияли алмаган булырсың.

**V. Өйгә эш.**
- Өй эшен вариантлап бирәбез:
1. “Ата- аналарны, өлкәннәрне хөрмәт итү ничек итеп күз алдыгызга китерәсез?” дигән темага җавап әзерләп килергә.
2. Ата- аналар, өлкәннәр турында тормыштан мисаллар, хикәя, хәдисләрне эзләп табу.